وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№6 (103). 23 сентябрь 2011 / 25-шәүвәл-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Авыл имамнары чит илгә йөрми... ▷2◁



Сәбәп кенә булсын... ▷3◁



Дин тотучылар арасында югары әхлакка ия булучылар... ▷4◁

# ХАК ЮЛ



Адәм баласы ислам диненә нинди генә юллар белән килми. Шулар арасында дини гыйлем хакыйкатьне һәм дөрес юлны күрсәтүче маяк кебек. Шундый заманада яшибез ки, вакыт артыннан куып, берберебез белән ихластан сөйләшү өчен дә кайчак вакыт җитми. Ләкин вакыт тарлыгын дөньяга сылтау дөрес түгел, теләгең булса, намазга өйрәнергә, гыйлем алырга, мәчет-мәдрәсәләргә йөрергә мөмкинлек табып була. Мәчет каршындагы курсларда рухи яктан җитлеккән, тәҗрибәле остазлар гыйлем бирә. Бөтен кешенең дә мәдрәсәдә гыйлем алырга мөмкинлеге юк. Күп очракта бу вакытның кысан булуына бәйле. Ә менә мәчет каршындагы әлеге курсларга күпләр бик теләп йөрер иде. Шуңа да әлеге курсларда гыйлем бирүче мөгаллимнәрнең куйган хезмәте икеләтә бәһале һәм зур әһәмияткә ия. Шуны истә тотып, 27 сентябрьдә уздырылачак мәчет каршындагы мөгаллимнәрнең республика киңәшмәсендә остазларыбыз, бер-берсе белән танышып кына калмыйча, тупланып килгән күпьеллык тәҗрибәләре белән уртаклаша һәм яңа программалар белән таныша алыр дип өметләнәбез. Бүгенге көндә республикабызда меңнән артык мөгаллим бар, шуларның өч йөзе әлеге киңәшмәдә катнашыр дип көтелә. Киләчәктә мондый очрашуларга тагын да зуррак өметләр баглыйбыз, үстерү, киңәйтү өстендә эшләрбез, дип ышанам.

Күптән түгел генә башкалабыз Казанда ачылган Имамнарның квалификациясен күтәрү үзәге турында да билгеләп үтмичә булмый. 2011 елдан башлап Татарстанның мең биш йөздән артык имамы ике атналык әлеге курсларны ел саен үтәргә тиеш булачак. Бер уйлаганда, китап кибетләрендә дини әдәбият та җитәрлек, интернетны әйтеп тә торасы юк - кирәкле материалларны аласың да, вакытың һәм ихтыяр көчең җиткәнчә, белемеңне тирәнәйтә һәм рухи үсешкә ирешә аласың. Ләкин хикмәт анда түгел, без кешеләрне яшәү мәгънәсен табарга, үсәргә, камилләшергә, дин юлына беренче тапкыр аяк басучыларга рухи ярдәм күрсәтергә тиешбез. Чөнки мондый очрашулар аша без шәхес формалашуда катнашабыз, активлыгыбызны арттырабыз. Әлеге үзәкне оештыруның төп мәгънәсе нәкъ менә шунда да инде. Күпчелеге авылдан булган имамнарыбызга шундый зур вазифа йөкләнә... Инша Аллаһ, өметләребез акланыр дигән ышанычта калам!

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Дидия нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# "ӨЧЕСЕ", "ҖИДЕСЕ", "КЫРЫГЫ"...

**Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһ исеме белән. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) һәм аның гаиләсенә, сәхабәләренә сәламнәребез барып ирешсә иде.**

Кеше мәңгелек дөньяга күчкәннән соң "өчесе", "җидесе", "кырыгы"н үткәрергәме? Соңгы елларда Татарстан мөселманнары арасында шул хакта бәхәсләр куера башлады. Өммәтебез бер фикергә килә алмаганга, бу мәсьәлә көннән-көн актуальләшүен дәвам иттерә. Шул сәбәпле, газета укучыларыбыз белән берлектә әлеге гореф-гадәтнең рухи тормышыбызда тоткан урынын анализлап карарга булдык. Бу традициябезне хупламаучыларның фикерләренә колак салыйк.

Коръәни-Кәримдә һәм пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтендә бу мәҗлесләрне үткәрү ярамаганлыгы турында катгый дәлилләр юк. Бер генә хәдистән дә, Аллаһ Китабыннан да: "Я, мөэминнәр, сакланыгыз!" яисә "Бу гамәлдән ерак торыгыз!" дигән юллар таба алмабыз. Шуңа күрә, бу гамәлне хәрамга чыгарырга хакыбыз юк. Ә белә торып шундый хөкем чыгарган кеше диннән ерак торучы яисә кяфер булып саналырга мөмкин.

Традициябезне кабул итмәүчеләр гап-гади дәлилләргә таяна. Алар пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Һәрбер яңалык (бидгать) җәһәннәмдә", - дигән хәдисен китерә. Ләкин алар рәсүлебезнең (с.г.в.) тагын бер хәдисен истән чыгара. Хәдистә сөннәтнең ике төре хакында әйтелә: "Кем ислам динендә яхшы сөннәт калдырды" һәм "Кем динебездә начар сөннәт калдырды".

Белүебезчә, "сөннәт" дигән сүз гарәпчәдән "юл", "традиция" дигән мәгънәгә ия. Димәк, традицияләр уңай һәм тискәре була ала.

Югарыда китерелгән дәлилләрне күздән кичергәннән соң, объектив анализ ясауга күчик.

***1. ТУГАННАР БЕЛӘН КҮРЕШҮ.***

Гадәттә, бу мәҗлесләрдә мәетнең якыннары җыела. Алар арасында бик ерактан кайтканнары да була. Димәк, бу гамәл - озак вакытлар бер-берләрен күрмәгән кешеләрнең аралашуына, туганлык җепләрен ныгытуга китерә. Шәригатебездә туганлык җепләрен саклау нинди урын били соң? Бу сорауга хәтта иң аз гыйлемле мөселман кешесе дә җавап бирә алыр. Бу - фарыз гамәл. Туганлык җепләрен өзүчеләргә Аллаһы Тәгалә "Рәгыд (Күк күкрәү)" сүрәсенең 25 нче аятендә болайрак мөрәҗәгать итә: "Аллаһка итәгать итәргә гәһед (ант) биргәннән соң гәһедләрен бозучылар, Аллаһы Тәгалә өзмәскә кушканнарны өзеп, җир өстендә төрле бозыклыклар кылучыларга Аллаһның ләгънәте булачак һәм аларга бик яман йорт - җәһәннәм әзерләнгән" (Бу урында һәм алга таба Ногмани тәфсире файдаланылачак).

***2. СӘЛАМ БИРҮ.***

Кешеләр бер-берләре белән очрашкач, билгеле, сәлам бирергә тиеш. Динебездә исәнләшү тәртибенә караган хөкем шундый: беренче булып сәламләгән кеше сөннәт гамәлен үтәсә, җавап кайтарганы өстендәге фарызны үтәгән була. Бу мәсьәләдә Коръәни-Кәрим: "И, мөэминнәр! Әгәр сезгә берәүдән бүләк бирелсә, бүләк бирүчегә үзегез алган бүләк хәтле яки артыграк итеп бирегез! Шиксез, Аллаһ һәрнәрсәне хисап кылучы. (Бүләкнең һәр мөэмин өчен мөмкин һәм лязем булганы сәлам бирү һәм кайтарудыр)" ("Ниса (Хатыннар)" сүрәсе, 86 нчы аять).

***3. КАЙГЫ УРТАКЛАШУ.***

Әлбәттә, мәҗлескә җыелучылар бу көннәрдә кайгыхәсрәттә калган гаиләнең борчуын уртаклаша. Шәригать буенча, бу гамәл - сөннәт санала. Моңа мисал итеп күпсанлы хәдисләр китереп була. Ән-Нәсаи җыентыгында бирелгән хәдистә бер ир-ат хакында сүз бара. Ул кечкенә улы белән пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) дәресләренә йөргән була.



Бер көнне аның улы вафат була һәм ул рәсүлебезнең (с.г.в.) дәресенә килә алмыйча кала. Аллаһ илчесе үзенең сәхабәләреннән аның турында белешә. Баласы үлгәнен ишеткәч, пәйгамбәребез (с.г.в.) ата кешенең кайгысын уртаклашу нияте белән аның янына китә.

***4. ВӘГАЗЬ СӨЙЛӘҮ.***

Мәҗлес барышында имам үтемле вәгазь сөйләп, нәсихәтләр бирү белән мәшгуль булырга тиеш. Коръәни-Кәримнең "Нәхел (Умарта кортлары)" сүрәсенең 125 аятендә: "И, Мөхәммәд галәйһиссәлам һәм аның өммәте! Раббыңның юлы булган ислам диненә Коръән дәлилләре, тәэсирле яхшы вәгазьләр белән кешеләрне чакыр(-ыгыз), кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен иң күркәм юл белән көрәш(-егез)! Әлбәттә, синең Раббың Аның юлыннан адашкан кешеләрне һәм Коръән юлында булган хак мөэминнәрне белә", - дигән сүзләр бар. Шуңа күрә дә җәмәгатьнең белем дәрәҗәсенә карап, имамның вәгазь сөйләп Аллаһ юлына чакыруы - фарыз гамәл санала.

**5. КОРЪӘН УКУ.**

Бу - сөннәт гамәл. Имам Мөслим җыентыгында: "Коръән укыгыз! Ул Кыямәт көнендә үзен укучыларга шәфәгатьче булыр", - дип язылган.

***6. ДОГА КЫЛУ.***

Коръәни-Кәримдә: "Раббыгыз әйтте: "Миңа гыйбадәт итегез һәм дога кылыгыз, Мин кабул итеп әҗерен бирермен". Әмма Миңа гыйбадәт кылудан тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр, кечкенә булып хур булган хәлдә, җәһәннәм утына тиз эләгерләр", - диелгән ("Мөэмин" сүрәсе, 60 нчы аять). Дога, әгәр дә кеше яхшыны теләсә, кешенең теләге белән бәйле булырга, рөхсәт ителгәнне сораса - ихтыяри, ә инде бурыч итеп йөкләнгән әйберләрне сорса, мәҗбүри булырга мөмкин.

***7. СӘДАКА ӨЛӘШҮ.***

Нигездә, ул - сөннәт дәрәҗәсендә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): "Хөрмә төшенең бер генә бөртеге белән булса да, үзегезне җәһәннәм утыннан саклагыз", - дип әйткән. Без бу хәдистән кечкенә күләмдәге хәер хакында сүз барганлыгын аңлыйбыз.

***(Ахыры 3 нче биттә.)***


## Рөстәм Миңнеханов Казанның тарихи үзәгенә дүртенче сәяхәтен ясады

***18 сентябрь көнне Татарстан президенты Рөстәм Миңнеханов Казанның тарихи үзәгенә дүртенче сәяхәтен ясады.***

Россиянең тарих һәм мәдәният истәлекләрен саклау җәмгыятенең Татарстан бүлеге әгъзасы Олеся Балтусова белән бергә президент Казанның Мөштәри, Маяковский, Ульянов-Ленин һәм шул тирәдәге башка зур булмаган урамнардагы тарихи биналарны һәм агачтан эшләнгән ядкарьләрне дә карады, дип хәбәр итә business-gazeta.ru сайты.

Әлеге сәяхәт вакытында президент шәһәр үзәгендә Казанның архитектура матурлыгын бозып силикат кирпечтән күпкатлы йортлар төзелүгә ризасызлык белдерде. Миңнеханов бу биналарның хуҗалары кем булуны ачыкларга һәм аларны җавапка тартырга чакырды.

## Балык бистәсендә гошер сәдакасы җыелды



***16 сентябрьдә Балык бистәсе районының Тәберде Чаллысы һәм Биектау авыллары хуҗалыкларыннан гошер сәдакасы җыеп алынды. Җыелган уңыш якын көннәрдә мохтаҗларга таратылачак. Район халкы гошер сәдакасын елдагыча мулдан җыйган иде. Тәберде Чаллысы авылыннан гына да җитмеш капчык бәрәңге Ислам дине кабул ителүнең мең ел исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсенә озатылды. Әлеге фарыз гамәлне үтәүдә авыл халкы бик теләп катнаша икән.***

Балык бистәсе районы имам-мөхтәсибе Сәүдәхан хәзрәт Гайнетдинов: "Үткән атнаны районның Җәмигъ мәчетендә барлык район имамнарының җыелышы үтте, биредә гошер сәдакасы турында да сүз кузгатылды. Якын көннәрдә башка авыллардан да гошер сәдакаларын җыеп бетерәчәкләр, Инша Аллаһ. Без аларны да мохтаҗларга тапшырырбыз", - дип ассызыклап үтте.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең беркетмәләр бүлеге җитәкчесе Илшат Насыйбуллин гошер сәдакасын җыеп тапшыруны тиешенчә оештырган, авылларда ислам динен үстерүгә үзләреннән өлеш керткән имамнарга Диния нәзарәте исеменнән рәхмәт хатлары тапшырды.

**DUMRT.RU**

## *Китап – иң яхшы бүләк!*

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге республикабызның мәчет һәм мәдрәсәләре каршында китапханәләр оештыру максаты белән китаплар җыя.***

Һәркемнең дә шәхси китапханәсендә берничә кат укылган яисә, гомумән, файдаланылмыйча яткан китаплары бардыр. Әлеге китапларны мәчет һәм мәдрәсәләргә бирсәк, алардан башка дин кардәшләребез дә, шулай ук яңа гына динебезгә якынайганнар да файдалы белемнәр ала алыр иде.

Игелекле чарада катнашырга теләге булганнарны Казан шәһәре, Лобаческий урамы, 6 нчы йорт (3 нче кат, 7 нче бүлмә) адресы буенча көтеп калабыз. Китапларны җыю агымдагы елның 16 ноябренә кадәр дәвам итәчәк.

Барлык сораулар белән дә +7 (843) 236-52-12 яки 89872639889 телефон номерлары аша бүлек җитәкчесе Гөлнара Садыйковага мөрәҗәгать итә аласыз. Электрон почта адресы: sadykova-g@mail.ru.

**DUMRT.RU**



# Авыл имамнары чит илгә йөрми...

## (Мәхәллә тәҗрибәсе)



***"Милли тормыш һәм дин" дип аталган форумда уздырылган секциядә Балтач районында егерме ике ел имам булып эшләүче Татарстан Республикасы баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевны күпләр йотлыгып тыңлады. Ул үз мәхәлләсен Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән тәкъдир дип саный: "1988 елны авылга икътисадчы булып кайттым һәм мәктәптә мөмкинлек тугач, директор белән сөйләшеп, балалар укыта башладым.***

Шуннан соң әкрен генә эшне башлап җибәрдек. Директор: "Физика укытам, чөнки минем дипломым бар, синең берәр кәгазең бармы соң?" - дип әйтте. Имтихан биреп, имамлыкка шәһадәтнәмә алып кайттым. Указлы имам булып эшли башлаганга быел егерме бер ел тула. Монда утыручылар арасында яше буенча миннән өлкән кешеләр бардыр, әмма 21 ел имам булып торганнары бик аздыр", - дип башлады үз сүзен Җәлил хәзрәт.

Җ.Фазлыев билгеләп узганча, мәхәллә тормышын алып бару - гөнаһ эшләү сәләтен югалткач, мәчеткә йөри башлаган алты-җиде карт белән генә эшләү түгел. Әйтик, ул эшли торган мәхәлләдә 890 кеше яши. 190 пенсионер бар. 144 бала укый. 43 сабый балалар бакчасына йөри. "Менә шушы халык белән эшлибез. Шушы мәхәллә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән тәкъдир бит инде. Бу - безнең авыл, бу халык - безнең халык. Бу илләр - безнең илләр, бу бит инде безнең тәкъдиребез. Без риза булырга, халыкны яратырга, аның белән эшләргә тиеш", - дип белдерде ул.

Ә эшне ничек оештырырга соң? Бу хакта Җәлил хәзрәт бөртекләп сөйләде.

### Җәлил абзый Кыш бабайдан яхшырак...

- Иң беренче баскыч - балалар бакчасы. Яңа ел "бидгать", диләр. Кыш бабайны сүгә башладылар. Менә Согуд Гарәбстаныннан укып кайтты егетләр. Хәзер мәктәп балалары миннән сорый: "Ислам дине шулай курканыч динмени? Кыш бабай юк анда". Балаларга Кыш бабайны сүгеп, ислам диненә мәхәббәт уятып булмый. Кыш бабай юк ислам динендә. Әмма безнең халыкта ул традициягә кергән. Аны бүген генә чыгарып ташлап булмый. Башыма шундый фикер керде: нигә имамга үзен Кыш бабай итеп танытмаска? Менә берәр баладан: "Кем ул имам?" - дип сорасаң ул: "Кеше үлгәч килә торган бөкре карт", - дип әйтәчәк. Ике гает бәйрәме бар. Илле биш балага пакет тутырып, чапан-чалманы киеп, ураза һәм корбан гаетендә балалар бакчасына керәм. Алар залга җыелалар, белгәннәрен укып күрсәтәләр. Кыш бабайны кебек кесәмдә тәм-томнар... Күбрәк укыганына күбрәк бирәсең инде... Балалар бакчасына әби-бабайлар да килеп утыра, оныклары дога укыса, аларга да бүләк бирәбез.

Балалар бакчага биш ел йөри. Шулай итеп, бер елда ике тапкыр килсәң, ун тапкыр безнең белән очрашалар. Бала мәктәпкә килгәч: "Мулла начар", - дип сүксәләр дә, ул аны: "Яхшы кеше", - диячәк. Әле быел берсе: "Җәлил абзый, син Кыш бабайдан әйбәтрәк", - диде.

### Намаз укуда ярышалар

- Кайбер имамнар мәктәпкә чакырмаганга зарлана. "Беренче звонокта сөйлим әле дип, мәктәп директорына бардым , РОНОга бардым - каршылык күрсәттеләр", - дип әйтәләр. Минем вәгазьгә чакыруларын сораганым юк. Ничә малай, кыз керүен белешәм һәм бүләк әзерлим. Чакырып түргә утырталар, сүз дә бирәләр. Унбиш балага бүләк биргәннән генә мәчетнең акчасы бетми. Балаларга дини китаплар бүләк итәбез.

Башлангычта "продленка" - "озынайтылган дәрес" бар. Мең сум акча түләп, бер укытучы тотам. Башлангычларга атнасына бер сәгать "продленка"га керә ул.

Унөч ел инде районыбыздагы егерме ике татар мәктәбендә ислам дине нигезләрен укытабыз. Димәк, бала бакчадан алып IX сыйныфка кадәр безнең белән.

Лагерьны төн куна торган итеп оештырмыйбыз. Иртәнге сәгать тугызга киләләр, 3-4 сәгать шөгыльләнәләр дә, өйлә намазыннан соң кайтып китәләр. Җиңелчә генә бер тапкыр ашатып алабыз. Баланы 24 сәгать мәчеттә тоттың ни, өч тапкыр ашаттың ни - аны барыбер ике сәгатьтән артык укытып булмый.

Барысы кырыкка якын бала йөри. Санап чыгардым: балаларны бер көн ашатыр өчен сигез йөз сум акча кирәк. Менә беренче көнне мин үзем күтәрәм дип, мең сум акча бирдем. Калган көннәрне ата-аналар күтәрә. Кемнәр акча алып килә, һәркайсына ашар алдыннан дога кылабыз.

Безнең мәчет кечкенә түгел: ике катлы, аның тагын мәдрәсә өлеше бар. Элек-электән ястү намазын яшьләр укый. Нигездә, X-XI сыйныф егетләре берсен-берсе чакырып ястүгә йөри. Шәкертләр дә китертәбез.

Балалар өчен Сабантуй уздырдык. Мәктәпнең бөтен чараларында катнашабыз. Быел намаз уку бәйгесе оештырдык. Бала тәһарәт алу тәртибен сөйли дә, кайсы намаз эләгә, шуны кычкырып укып күрсәтә. Бөтен хәрәкәтен тикшерәсең, "бисмилла" әйтәме, юкмы... Алар болай эшли, тегеләр тегеләй итә дип, нигә тавыш куптарып торырга, бала чактан ук намаз уку тәртибенә өйрәтик.

### Мәчеттә бердәмлек булсын

- Халыкны мәчет аркылы үткәрергә тырышабыз. Безнең мәчеттә табын әзерләрлек өстәл-урындык, савыт-саба бар. Пенсионерларны да, мәктәп балаларын да җыеп, авыз ачтырабыз. Авыл советына өч авыл карый, шунда 39 ятим бала, 26 инвалид исәптә тора. Уразада аларга ярдәм оештырабыз. Менә шулай иттереп, әкрен генә халык белән эшлибез.

Авыл мәчетләренә йөргән алты-җиде кеше шәһәрдә укыган йөз кешедән күбрәк ул. 240 мең кешелек шәһәрдә бер мәчет бар. Шунда җомганы биш йөзләп кеше укый, дип күкрәк кагалар. Ярты процент бит инде ул. 890 кешенең җитмеше килсә, ул ун процентка якын була. Ләкин без, авыл имамнары, күкрәк кага алмыйбыз. Әйтик, сез Казанның кеше күп йөри торган мәчетләрен алыгыз һәм бер якка шунда эшләүчеләрне аерып куегыз. Алар намазга түгел, эшкә килүчеләр. Икенче якка җимеш сатучыларны аерып куегыз. Аннары мәдрәсә шәкертләрен һәм авылдан килеп укый торган студентларны аерыгыз, шуннан соң анда берничә кеше генә калачак. Утыз-кырык бабай йөрми бит берсенә дә. Менә шуңа күрә имамнардан мәчеткә ничә кеше йөргәнен сораганым юк. Иң мөһиме - биш вакыт намазга мәчет ачылсын.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Татарстанда Динара хезмәттәшлек ассоциациясе төзү тәкъдим ителде

***20 сентябрьдә Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгында "Яшьләр арасында экстремизмны кисәтү чарасы буларак дини оешмаларның хезмәттәшлеге" дигән темага узган түгәрәк өстәл барышында шундый тәкъдим җиткерелде.***

Очрашуда ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе, Татарстанның төп конфессияләре, Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы вәкилләре катнашты.

ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин чараның башында хәбәр иткәнчә, әлеге түгәрәк өстәл "Экстремизмга юл юк" дип исемләнгән айлык кысаларында уза. "Без Татарстандагы төрле оешмаларда яшьләр белән эшләүнең ни рәвешле алып барылуы турында сөйләшергә һәм тәҗрибә уртаклашырга телибез", - диде ул. Түгәрәк өстәлдә катнашучылар Татарстанда динара диалог, массакүләм мәгълүмат чараларында этноконфессиональ проблемалар, конфессияара хезмәттәшлектә чит ил тәҗрибәсе һәм социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыру максатларында конфессияара хезмәттәшлеккә бәйле мәсьәләләр хакында фикер алышты.

Россия православие чиркәвенең Казан епархиясе яшьләр бүлеге җитәкчесе Александр Хохлов үз чыгышында ассызыклап үткәнчә, динара диалог хакында сөйләгәндә дини тәгълимат хакындагы искәртмәләрдән аңлы рәвештә качарга кирәк. "Диалогны социаль һәм гуманитар проблемаларны хәл итү нигезендә кору зарур", - дип билгеләп үтте А.Хохлов.

Россия ислам университетының табигый-гуманитар фәннәр кафедрасы өлкән укытучысы Марат Сәлахов, үз чиратында, төрле социаль проектларның төрле дин вәкилләрен берләштерүен билгеләп үтте. "Безнең диннәр Хак Тәгаләне төрлечә аңлый, әмма тынычлык һәм яхшылык дине барыбыз өчен дә бер", - диде Марат Сәлахов.

Ул Динара хезмәттәшлек ассоциациясе төзү идеясен җиткерде.

Шундый ассоциация булдыру ниятен түгәрәк өстәлдә катнашкан башка конфессия вәкилләре дә хуплады.


"Без, түгәрәк өстәлдә катнашучылар, фикер алышулар барышында иҗтимагый берләшмә төзү турында уртак фикергә килдек. Әлеге берләшмәнең шигаре түбәндәгечә булырга мөмкин: "Безнең диннәр Ходайны төрлечә аңлый, әмма яхшылык дине барыбыз өчен дә бер", - дигән фикерне җиткерде очрашуда катнашучылар чара ахырында. "Әлеге инициатива хупланыр дип уйлыйм", - диде Марат Гатин.

Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы башлыгы урынбасары Нурия Беломоина этноконфессиональ тематиканы яктыртуда Татарстан массакүләм мәгълүмат чараларының эшчәнлеге хакында сөйләде. Ул үзенең чыгышында этноконфессиональ тематикага барлык мәгълүмат чаралары да мөрәҗәгать итүен билгеләп үтте.

Нурия Беломоина 2005 елдан бирле Төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чаралары конгрессы үткәрелүен ассызыклап узды. Әлеге форумда катнашучылар Россия, БДБ илләрендә төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чараларының хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары хакында фикер алыша, үзара тәҗрибә уртаклаша.

Түгәрәк өстәлне оештыручылар мондый очрашуларның алга таба да узачагын билгеләп үтте, - дип яза tatar-inform.ru сайты.

***Алия ҖАМАЛИЕВА.***



# Сәбәп кенә булсын...

**Җәмгыятебездә мөселманнарга карата гадел булмаган караш, берәр төрле җинаять кылынса, гаеплеләрне иң беренче мөселманнар өммәтеннән эзләү, төрле шартлату, җәбер-золымнарда гаепләү яшәп килә.**

Кызганыч ки, республикабызда да мөселманнар турында дөрес, хакыйкый фикер әлегәчә урнашып бетмәгән. Әлбәттә инде, радио-телевидение, интернет челтәрендә дә төрле яла ягулар була торып, урам чатларындагы чегән балаларының дога укып йөрүләре берниндидә уңай фикер барлыкка китерә алмый...

## Бүрәнәнең юан башы - безгә...

Чегән балаларының мәчет яннарында (бигрәк тә җомга көннәрендә) җыелышып утырулары мәчеткә байлар яисә юмартлар йөргәннән түгел. Алар бит барысын да яхшы аңлый: мәчеткә кергән кешенең күңеле нечкәрә, дөньялыкта яхшы, изге гамәл кыласы килә башлый, хәтта кесәсендәге соңгы тиенен дә чыгарып бирергә риза. Шуннан файдаланалар да инде. Автобус эчләрендә дога укып (дөрес укысалар иде әле!), хәер җыеп йөрү сукбайлар өчен җиңел акча эшләү ысулы булса, күпләрдә моның аркылы мөселманнарга карата хәер сорашучы, мескен, сукбай дигән фикер барлыкка килә. Ни кызганыч, бүгенге көндә исламга карата тискәре фикер уяту төрле яклап дәвам итә...

## Мин террорчы түгел!

Бигрәк тә ислам канунннары буенча киенгән мөслимәләргә яисә сакал җибәргән хәзрәтләребезгә башка милләт вәкилләре тарафыннан шикле караш ташлау бар. Бер танышым ачынып бер вакыйга сөйләгән иде:

"Гомуми лекциядән соң, тулай торакка кайтырга дип автобус салонына кердем. Шулвакыт дәрестә кайбер сәбәпләр аркасында була алмаган төркемдәшем шалтыратып, университеттагы яңалыкларны сораштыра башлады: нинди яңалыклар, сораулыклардан кайсыларын алып аттылар һ.б. турында сөйләшеп барабыз.

- Алман телендәге сорауларның соңгы икесен - терроризмга кагылышлыларын алып аттылар, - дип яңалыкларны җиткерергә ашыктым...

Маршрут эчендәге сәер карашларны азрак тойдым, әмма артык игътибар бирмәдем. Рәхәтләнеп татарча сөйләшүне дәвам итәбез. Дустыма:

- Бомбалар ясамадыңмы? - дип әйтергә дә өлгермәдем (имтиханга ясала торган "бомба" турында сүз бара иде), баягы сәер караш тагы да көчәйде, бер абзыйның аягүрә басып, нәрсәдер эшләргә җыенганын абайлагач, тиз генә сөйләшеп тә бетермичә, телефонымны сүндереп, хәлне дөрес аңламауларын әйтергә, барысын да аңлатырга туры килде..."

## Коръән - миф?

Шәһәр үзәгендәге "Кольцо" сәүдә үзәгендәге китап кибетенә студентлар, гомумән, китап сөючеләр бик теләп йөри. Әлеге китап кибетенә бәйләнешле бер вакыйга истә калган. Китаплар "Чит ил әдәбияты", "Медицина", "Тарих" һ.б. бүлекләргә киштәләп бүленгән. "Дин" исеме астындагы бүлектә православие, будда дине китаплары урнаштырылган. Янәшәсендә "Мифы" дигән бүлек бар һәм нәкъ менә шушы мифлар бүлегендә Коръән, хәдисләр, ислам диненә кагылышлы китаплар... Баштарак, бәлки урнаштырылып бетмәгәндер, дип уйлаган идек, инде ничә кергәндә дә шул сәер күренешкә тап булгач, кибеттәге җаваплы консультантны чакырып, Коръәннең ни өчен мифлар бүлегендә торуын сораштырдык. Сорауга ничек тә җавап бирергә белмәгән яшь туташ:

- Ялгыш берәрсе куйгандыр, - дип тизрәк китү ягын карады. Тик әлеге бүлектә бер генә китап түгел, ә тулы бер шкаф ислам диненә багышланган иде. Иптәшем белән бер-беребезгә карадык та сүзсез калдык...

Шулай да кергән саен әлеге сорауны бирә башладык, бигрәк гаҗәп бит инде - исламны миф итеп карау... Ярты елдан артык мифлар бүлегендә торган Коръән, ниһаять, диннәр бүлегенә күчерелде. Консультантлар безнең сорауларыбызга җавап биреп туйдылар булса кирәк. Ә шулай да китап кибетенә еш йөрүчеләрнең күңелендә Коръән китабы, бәлки, миф буларак сакланып калгандыр да... Кемнеңдер игътибарсызлыгы аркасында (чыннан да игътибарсызлык булса!) мөселманнарга, ислам диненә карата ихтирамсызлык күрсәтү бит бу!

Дөресен генә әйткәндә, җәмгыятебез ислам дине турында тирән фикер йөртми. Шуның нәтиҗәсендә, юктан гаеп эзләү, кешеләрнең ялгышларын дин белән бәйләп карау башлана. Бер караганда, шундый чылбыр барлыкка килә кебек: кешеләр ислам турында белми һәм начар уйларга мәҗбүр була, ә начар уйлавы сәбәпле, динне өйрәнергә теләми. Димәк, безгә, хак юлны табучыларга, нинди юллар белән булса да әйләнә-тирәдәгеләрнең ислам дине турындагы фикерләрен камилләштерү буенча эшләргә кирәк.

**Алинә БИКМУЛЛИНА**



# Җәһәннәм, җәннәт һәм ярату,
## яки Ни өчен без җәһәннәмнән куркырга тиеш?

**Чыннан да, ни өчен кеше җәһәннәмнән куркырга тиеш? Әгәр дә без төрле китаплардан җәһәннәмне тасвирлауны укысак, анда төп фикер булып, гөнаһ кылучыны анда көткән авыртулардан төрле куркыныч газаплар кичерәчәге тора (өзекләр китермим, белмәгәннәр үзләре кызыксынырлар).**

Кеше өчен авырту нәрсә соң ул һәм аны безгә ничек аңларга? Гомумән, ул нәрсә өчен кирәк? Барысы да гади - авырту организмга нәрсәдер читтән эләккәнне белдерүче сигнал булып тора һәм ул кешене үлемгә китерергә мөмкин.

Җәһәннәмгә кеше үлгәннән соң эләгә. Ә аннан соң кая? Беркая да түгел - мәңге ялкынланып торучы җәһәннәм, анда кеше гомере буе курыккан һәм котылгысыз рәвештә якынлашкан нокта - үлем юк (ул инде артта).

Кеше бит, туганнан алып, туры юл белән үлемгә таба бара. Гомере дәвамында кеше нәрсәгә дә булса омтылып яши һәм һәрвакытта да үзенең максатына ирешкәннән соң, ул яңасын сайлый. Әгәр дә кеше яшәвенең максатын югалтса, ул сула һәм үлә.

Ә җәһәннәмдә нәрсә соң? Иге-чиге булмаган мәңгелек газаплануларммы? Ни өчен һәм нәрсә өчен газаплanулар? Сиңа берни белән дә янамаган чыдап булмаслык авыртудан газаплануны? Бу авыртумыни?

Иптәшләр, нәрсә куркытасыз соң? Җәһәннәм белән куркытучы кешеләрне тыңлаганда миңа кызык булып тоела. Бу Аллаһының мескен бәндәләре, иңдерелгән тасвирлаулардан тыш, җәһәннәм белән җәзалау турында нәрсә белә ала соң?

Һәм, гомумән, нинди метод бу? Газапларыннан курыкканга гына ышанырга мы? Оятсызлык һәм примитивлык.

Курку гына ышану чыганагы булырга мөмкинме?! Әлеге хисләрнең ихласлыгы нинди? Җәннәт белән дә шулай ук. Тасвирлаулар буенча, ризыклар җитәрлек (җиләк-җимешләр), рәхәтлек, ә ир-атлар өчен, мәсәлән, зур күзле хур кызлары…

Иптәшләр, зур күзле хур кызлары һ.б. җир сылулары белән күңелне күрер өчен, вакытны бу дөньяда да күңелле үткәрергә була. Бу бүләкләү дип аталамы? Бу очракта кеше эчке аңы белән бу дөньяда булмаса да, "теге дөньяда" күңел ачарга омтыла. Бигрәк тә анда елгалар да эчүчеләр өчен шәрабтән булса…

Кыскасы, кешенең эгоистик уйлары җәһәннәмгә түгел, ә җәннәткә эләгү омтылышы белән булырга тиеш.

Ә ярату ничек соң? Аллаһы Тәгаләне, яхшылыкны, чисталыкны, хаклыкны ярату? Кеше югары көчнең ризалыгына эгоизмы һәм үзенең җаны курыкканы өчен түгел, ә яратуы аркасында омтыла аламы?

Ни өчен Аллаһы Тәгаләнең боерыкларын Аның канунннары белән тактта булу һәм Аңа ярату теләге белән үтәргә ярамый? Әйләнә-тирәдәге бар нәрсәне матур һәм гармонияле рәвештә тудырылуын күреп, ышанырга. (Сүз уңаеннан, кеше үзенең куллары белән яхшырак һәм камилрәк берни дә барлыкка китерү мөмкинлеге булмаган килеш бу гармонияне бозарга гына сәләтле.) Бу дөньяны барлыкка китергән Югары Көч белән соклanудан туган ярату. Бу дөнья - Югары көчләрнең барлыгына ачык дәлил…

Гаҗәп нәрсә бит бу.

**Данис ГӘРӘЕВ**



# "ӨЧЕСЕ", "ҖИДЕСЕ", "КЫРЫГЫ"...

(Ахыры. башы 1 нче биттә.)

*8. КИЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕ, КУНАКЛАРНЫ ТУКЛАНДЫРУ.*

Бу да сөннәт гамәлләрдән санала. Бер хәдис безгә түбәндәгеләрне ирештерә: "И, кешеләр! Сәлам таратыгыз, бер-берегезне туклandырыгыз, туганлык җепләрен саклагыз, кешеләр йоклаганда төнге намазлар үтәгез һәм сез җәннәт әһеле булырсыз".

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, барлык хөкемнәр буенча да нәтиҗә ясасак, аларның сөннәт дәрәҗәсеннән башлап хәтта фарыз хөкеменә якын булуына төшенербез. Шулай да, төп нәтиҗә чыгарырга ашыкмаска һәм бу мәҗлесләрнең вазыйфалары хакында фикерләп карарга тәкъдим итәм.

Миңа калса, мәҗлесләрнең ничек узуына карап, "өчесе", "җидесе", "кырыгы"н үткәрүне массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлеге яисә кайбер иҗтимагый җыеннар белән дә чагыштырып фикер йөртергә мөмкин булыр иде. Билгеле булганча, Мәккә шәһәрендә яшәгәндә пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) ислам динен халыкка җиткерү өчен хаҗ вакытын оста файдаланган. Бу вакытта төрле кабиләләр Мәккәгә килә торган булган. Икенче төрле итеп әйткәндә, Аллаһ илчесе халыкның күпләп җыелган вакытын сайларга омтылган.

Хәзерге вакытта динебезне тарату мөмкинлекләре бик күп. Мисал өчен, газета-журнал мәкаләләре, радио-телевидение тапшырулары, интернетта эш алып бару, кесә телефоны һ.б. аша. Без исә үз чиратыбызда, искә алып үткән мәҗлесләрнең дә дәгъват буларак аз роль уйнамавын искәртик. Әбибабаларыбыз, әти-әниләребез татар мохитендә динебезнең сакланып калуында мондый мәҗлесләрнең зур урын тотканын яхшы белә. Бүгенге көндә дә әлеге вазыйфаны мондый төрдәге мәҗлесләр үтәп килә.

Кыскасы, "өчесе", "җидесе", "кырыгы" мәҗлесләре бик файдалы чара булып хезмәт итә. Шунысын да истә тотарга кирәк: безнең бу мәҗлесләрне ни дәрәҗәдә дөрес оештыруыбыз да зур роль уйный. Ифтар кылу өчен пычак белән ипи кисеп булган кебек, бу корал белән кеше гомерен дә өзеп була. Шулай ук, әлеге мәҗлесләр белән без кешеләргә ислам динен төшендерә алган кебек, аларны диннән читләштерергә дә мөмкинбез. Барысы да ниятебезгә кайтып кала. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Барлык гамәлләр дә нияткә карап бәяләнә", - дигән хәдисен искә төшерик. Әгәр дә ашка килгән имамны мәҗлестә ризык һәм сәдака гына кызыксындырса, аның бу гамәле гади мөселманнар өчен ямьсез күренеш булып тоелып, аларны диннән читләштерергә мөмкин. Әлбәттә, мулланың бу рәвешле гамәл кылуы дөрес түгел, бу - динебездә тыелган. Монысын бидгать дип атарга да мөмкин.

Ләкин хәзрәт үз вазыйфаларын ихластан үтәп, ашка динебезне тарату нияте белән генә килеп, кирәкле аять-хәдисләрне, гыйбрәтле вакыйгаларны сөйләп, үтемле вәгазь укып, күркәм дога кыла алса, аның бу гамәлләре аша кешеләр иманга килер һәм мондый мәҗлесләрнең кыйммәте фарыз дәрәҗәсенә ирешә алыр, Инша Аллаһ.

Тормышыбыз чынбарлыгыннан чыгып, югарыда китерелгән тәкъдимнәрне гамәлгә кертә алсак, динебез милләтебездә тагын да зуррак үсешкә ирешер, дигән өметтә калам.

***Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,***
***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары***
***(Мәкаләне islam-portal.ru сайтыннан Айсылу Юлдашева тәрҗемә итте)***



# КЕЧЕ СОН МӘДРӘСӘСЕ

***Батырша восстаниесеннән, Емельян Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар сугышыннан курыккан патша хөкүмәте Идел-Урал буендагы халыкларга, шул исәптән татарларга карата да кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр була. Мәсәлән, 1789 елда Уфада бөтен Россия мөселманнарының дини идарәсе - Диния нәзарәте төзелә, мәдрәсәләр ачарга рөхсәт бирелә. Татар халкына гыйлем-мәгърифәт белән шөгыльләнү өчен дә берникадәр мөмкинлекләр барлыкка килә. XVIII гасыр ахырында Кышкар, Мәңгәр, Сатыш мәдрәсәләре белән беррәттән Кече Сон авылында да мәдрәсә ачыла.***

Халкыбызны аң-белемле итүдә, милли культурабызны үстерүдә Кече Сон мәдрәсәсе зур роль уйнады. Караңгылык, хорафат, милли дошманлык һәм деспотизм хөкем сөргән заманда яктылыкка, мәгърифәткә чакырып янган якты маяк булды ул.

Татар галиме Ризаэддин Фәхреддин үзенең "Асар" исемле хезмәтендә Кече Сон мәдрәсәсенең мөдәррисләрен санап китә. Фәхреддин бине Мөхәммәтсадыйк бине Габдерәфыйк әс-Суни 1803 елда туа. Ул Кече Сонда имамлык һәм мөдәррислек итә, 1868 елда 65 яшендә вафат була. Фәхреддин урынына имам һәм мөдәррис булып улы Юныс кала. Ул мәдрәсәдә шәкертләр укытып 1900 елның 25 маенда, 58 яшендә дөньядан китә. Юныс урынына улы Госаметдин имамлык һәм мөдәрислек итә. Ул 1870 елның 20 гыйнварында туа һәм 1920 елда вафат була. Госаметдин хәзрәтнең Мәүләхан һәм Габдрахман исемле уллары кала.


Мәдрәсәнең соңгы мөдәррисе - Мәүлә-әсән. Ул 1984 елда Алма-Атада үлә. Әтисе үлгәндә Габдрахман яшь була. Ул берникадәр вакыт Мамадышта белем ала, остазлык итү белән шөгыльләнә. 1980 елда Ташкенттан кайтып авыл картларыннан китаплар алып китә.

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң Госаметдин хәзрәт гаиләсен гомер иткән йортыннан куып чыгаралар. Мәдрәсә белән янәшә урнашкан бу мәһабәт йортта колхоз идарәсе, авыл Советы һәм почта урнаша. Бу йорт соңгы елларда гына сүтелде.

Аксакалларның әйтүенә караганда Фәхретдин хәзрәт тумышы белән Саурыш тирәсендәге авылларның берсеннән була.

***Ранил ТАЛИПОВ.***
***Мамадыш районы***
*(Ахыры киләсе санда.)*

# Алхәбәр: II Саматов укулары



***12 октябрьдә, татарның күренекле дин әһеле, галим Габделхак хәзрәт Саматовның туган көне уңаеннан, II Саматов укулары оештырылачак. Әлеге форумда хәнәфи мәзһәбе өйрәтүләре, ислам тарихы, татарлардагы мөселман мәдәниятенең этник һәм төбәк үзенчәлекләре, Габделхак хәзрәт Саматовның дини өйрәтмәләре һәм күпкырлы эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр каралачак.***

I Саматов укулары 2010 елда, ягъни татар халкының күренекле дин әһеле, Татарстанның беренче казые Габделхак хәзрәтнең тууына 80 тулу уңае белән уздырылган иде. Бүгенге көндәге имамнарның һәм дин әһелләренең бер өлеше - нәкъ менә Габделхак хәзрәтнең шәкертләре.

Әлеге форум кысаларында Г.Саматов исемендәге "Рухи мирас" премиясен тапшыру да күздә тотыла. Бәйгедә катнашырга теләгән дини һәм иҗтимагый мөселман оешмалары гаризаларны info@dumrt.ru адресына җибәрә алалар. Премияләр ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең комиссия әгъзалары тарафыннан билгеләнәчәк.

# Дин тотучылар арасында югары әхлакка ия булучылар... мөселманнар!

**Югары әхлак нормаларыннан чыкмаган күпчелекне мөселманнар тәшкил итә. interfax.ru мәгълүмат агентлыгының якынча бер ел элек дөнья күргән статистик мәгълүматларына караганда, ислам динен тотучылар арасында түбән мораль статус исемлегенә йөз респондентның бары тик унҗидесе генә эләккән, ә калган сиксән өче урта һәм югары мораль статусны үзара тигез бүлешкәннәр.**



Нәкъ шушы күрсәткечләр православие дине вәкилләрендә түбәндәгечә билгеләнә: респондентларның ? азрагы түбән мораль статуска, 39 проценты - уртача, 31 проценты - югары мораль статуска ия. Сораштыру үткән башка конфессия вәкилләрендә түбән, уртача һәм югары күрсәткечле мораль статуслар чагыштырмасы якынча болайрак: 46%, 23% һәм 31%, ә атеистлар арасында - 32%, 43% һәм 25%. Илебез социологлары якынча 13% россиялеләрнең дини җыелышларга йөрүләрен хәбәр итә.

Дини җыелышлар сәяси һәм яшьләр оешмалары вәкилләренең, шул исәптән төрле фан-группалар очрашуларына караганда күпкә дәрәҗәле һәм популяррак.

Үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәсендә, социологлар шулай ук Россия җәмгыятен берләштерә алырлык идея җитмәүне дә ачыклаган. Сораштырулар күрсәткәнчә, 42% респондент көчле югары держава төзү максатында Россиядәге халыкларны берләштерүче идеяне күпчелек халык яклап чыгар дип уйлый. Җәмгыятьне социаль кыйммәтләр нигезендә берләштерүне яклаучы респондентларның саны 2001 ел белән чагыштырганда 50 процентка арткан, ә 1995 ел белән чагыштырганда, икеләтә арту күзәтелә (10 процентган 21 процентка). Моннан тыш, тикшеренүләр бүген һәр бишенче россияленең социалистик карашлы булуын да инкарь итми.

Хәзерге вакытта безнең илдә дини төркемнең искиткеч үсеш санын күрсәткән 20 миллионга якын мөселман яши. Әгәр дә шушы үсеш темплары дәвам итсә, 2100 елга Россиядә мөселманнар саны икеләтә артачак.

Америка Кушма Штатлары (США) Дәүләт департаментының дөньядагы дин ирекге турындагы махсус докладында исә Россиядә дин ирегенең кайбер очракларда чикләнүе турында да әйтелә.

2010 елның икенче яртыеллыгында 198 илдә дин ireген күзәтүче докладта түбәндәгеләр белдерелә: "Россия Федерациясенең Конституциясе илдә дин ирекге турындагы кануннарны тәэмин итә. Ләкин, чынлыкта, урыннарда чиновниклар аппараты бу ирекләрне чикли. Моннан тыш, Американың Дәүләт департаменты Россиядә дәүләт диненең булмавын, ә өстенлекле позицияне рус православие чиркәве алуын да ассызыклап уза.

***Алла КОРУСУН.***
***islam.ru сайтыннан алынды***

# Авыл имамнары чит илгә йөрми...

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)**

Безнең районда кырык мәчет бар. Балтачта һәр айның беренче пәнҗешәмбесендә имамнар җыелышы уздырыла. Бу - узган гасырның туксанынчы елларыннан бирле шулай. Сиксәнләп кеше җыела. Имамнар, абыстайлар, мәктәптән мөгаллимәләр, теләге булган кешеләр... Җыелабыз һәм ничек эшләргә кирәк икәнлеген киңәшләшәбез. Төрле авылда төрлечә китмәсен, бердәмлек булсын. Шуңа күрә кемнәрдер читтән килә икән (мисал өчен, мин бәрәңге җыярга килгән шәфигыйларны күздә тотам), тәнкыйтъ итмибез. Әмма үзебезнекеләр башка юлдан китмәсен, дип эшлибез. Берсе шәфигый яки мәлики, икенчесе хәнбәли булса, тәртип бетә. Үз йөзебезне югалта башлыйбыз, киләчәктә сугышып бетүебез бар.

## Мәчеттә акча юк икән, имамда була ул...

- Бер хәзрәттән: "Хәлең ничек соң?" - дигәч: "Әйбәт әле, бу арада бер-ике бай кеше үлде", - дип җавап биргән, ди. Авыл мәчетенең бөтен кереме - табыннардан. Бездә тәртип шундый: Коръән укыгач, сәдака өләшәләр бит инде, йорт хуҗасы сәдака өләшә дә, аңар дога кылабыз. Тагын кемнең сәдакасы бар - тастымал җәеп куябыз, я өстәлгә тәлинкә утыртабыз, шуңа салалар. Теге йорт хуҗасы биргәнне дә бөтен кеше уртага куя.

Кайберәүләр акча юклыктан зарлана. Мәчеттә акча юк икән, имамда була ул. Казанда да кайбер мәчетләрдә кайнар су юк. Хәзрәтләре: "Тәһарәт алган өчен акча түләгез", - дип кычкыра, ә үзләре чит илгә барып ял итә. Шуңа акчасы бар, ә мәчеттә җылы суы юк. Безнең авыл имамнарының чит илгә йөргәне юк, алай да мәчетләребездә су бар, Аллага шөкер. Су өчен акча сорамыйбыз. Әлбәттә, барысы да ал да гөл генә булып бетми, егерме ел эчендә төрле вакытлар булды, гайбәтенә дә кергәләделәр. Авыл җирендә имамнарның көнкүреше рентгентта торганны хәтерләтә. Халыкны яратырга кирәк, алар да сине яратыр.

***INTERTAT.RU***

**P.S. 24 сентябрьдә Җәлил Фазлыевның олуг юбилее. Сезне ТР мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән 55 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәбез! Республикабызда ислам динен үстерүгә керткән өлешегез, дин юлында фидакарьләрчә армый-талмый хезмәт күрсәтүегез өчен рәхмәтебезне җиткерәбез. Киләчәктә дә халык күңеленә татулык, иминлек, изгелек орлыклары сеңдереп озак яшәргә, ялгыш юлдан киткән кардәшләребезгә хак юлны табарга ярдәм итәргә язсын. Эшләгән эшләрегезгә Хак Сөбханәһү вә Тәгалә Үз рәхмәтләрен белдерер, Инша Аллаһ. Ходай Сезнең үзегезгә, гаиләгезгә, якыннарыгызга да күңел тынычлыгы, тән сәламәтлеге, бәхет-шатлык, тәүфыйк-һидаять, озын гомерләр насыйп әйләсен!**

**Киләчәктә дә динебезне ныгыту өстендә эшләргә насыйп булса иде.**

# Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 24.09.2011 | 05:03 | 06:31 | 13:02 | 16:35 | 18:38 | 20:06 |
| Якшәмбе | 25.09.2011 | 05:05 | 06:33 | 13:02 | 16:33 | 18:36 | 20:03 |
| Дүшәмбе | 26.09.2011 | 05:07 | 06:35 | 13:02 | 16:31 | 18:33 | 20:01 |
| Сишәмбе | 27.09.2011 | 05:09 | 06:37 | 13:02 | 16:28 | 18:30 | 19:58 |
| Чәршәмбе | 28.09.2011 | 05:11 | 06:39 | 13:02 | 16:26 | 18:28 | 19:55 |
| Пәнҗешәмбе | 29.09.2011 | 05:13 | 06:41 | 13:02 | 16:24 | 18:25 | 19:52 |
| Җомга | 30.09.2011 | 05:15 | 06:43 | 13:02 | 16:22 | 18:23 | 19:50 |

*Мәгълүматлар muslem.ru сайтыннан алынды*

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №6 (103) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 дәнә. **Заказ:** Е-506

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 16 сентябрь, 14.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**